СОВЕТ
ЭБАЛАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯБАЛАК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2020 ел Ябалак авылы № 6

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексынаһәм Россия Федерациясенеңаерым закон актларынаүзгәрешләркертүтурында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлыФедеральзаконның 1 статьясындагы 17 пунктының «б» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 117 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. 34 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Җирлек Советына бюджет турында карар проекты кертелгәннән соң кабул ителгән Җирлек бюджеты керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган Җирлек Советы карарлары нигезләмәләре чираттагы финанс елында агымдагы финанс елына һәм план чорына үзгәрешләр керткәндә агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.»

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http:// ebalak-kaybici.tatarstan.ru веб-адресыбуенча Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы Гыйзәтуллина М.Ф.